# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Иске-Тәрбит авыл җирлегенең Иске-Тәрбит торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**29 октябрь, 2019 ел.** **№ 1**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019 елның 26 октябрендә 10 сәгатьтә, 2019 елның 26 октябрендә 14 сәгатьтә, 2019 елның 29 октябрендә 10 сәгатьтә, 2019 елның 29 октябрендә 14 сәгатьтә этаплап булган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре белән «Сез 2020 елда яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Иске-Тәрбит авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?" соравы буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде :

а) *җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру*:

- авыл җирлеге торак пунктларындагы санкцияләнгән һәм санкцияләнмәгән чүплекләр территорияләрен чистарту;
- материаллар сатып алып күперләрне ремонтлау;

б) *җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру*:

- материаллар сатып алып, су челтәрләрен ремонтлау;

в) *җирлектәге торак пунктлар чикләрендәге җирле автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге* ;

- материаллар сатып алып, юлларны норматив хәлгә китерү;
- җирлектәге торак пунктлар чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту;

г) *ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту;*

- зиратларны чистарту һәм төзекләндерү,

« РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 361 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны -199, бу 55 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен гражданнар җыенында 199 катнашучы тавыш бирде; "Юк" позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Иске-Тәрбит авыл җирлегенең Иске-Тәрбит торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. «Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Иске-Тәрбит авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме

а) *җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру*:

- авыл җирлеге торак пунктларындагы санкцияләнгән һәм санкцияләнмәгән чүплекләр территорияләрен чистарту;
- материаллар сатып алып күперләрне ремонтлау;

б) *җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру*:

- материаллар сатып алып, су челтәрләрен ремонтлау;

в) *җирлектәге торак пунктлар чикләрендәге җирле автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге* ;

- материаллар сатып алып, юлларны норматив хәлгә китерү;
- җирлектәге торак пунктлар чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту;

г) *ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту;*

- зиратларны чистарту һәм төзекләндерү,

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Иске-Тәрбит авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек иткән,
Иске-Тәрбит авыл җирлеге Башлыгы В.Г.Тимофеев